ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

07.03.2023_ Казан ш. 52-од_

Хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урынына вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 10 февралендәге 359-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урынына вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты гамәлгә куючысы

функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен расларга.

2. Хокук һәм кадрлар белән эш бүлегенә әлеге боерыкны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив
эше буенча дәүләт комитетының
2023 елның 7 мартындагы 52-од
номерлы боерыгы белән
расланды

Хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урынына вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү
тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урынына вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү кагыйдәләрен билгели.

1.2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

Чара - хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урынына кадәр вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыру.

Гамәлгә куючы - Учреждениегә карата Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба - Гамәлгә ашыручы, Дәүләт комитеты);

субсидия - хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урыныа кадәр вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә акчаларны баш бүлүче һәм алучы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Гамәлгә ашыручы тарафыннан Учреждениягә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы

законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән бирелә торган субсидия.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

1.3. Субсидия Учреждениегә хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урынына кадәр вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыруга бәйле чыгымнарын түләү максатларында бирелә.

## 2. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидияләр алу өчен Учреждение Гамәлгә куючыга түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы белән расланган форма буенча субсидияләр алуга гаризаны;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатка бюджет чараларын бирү ихтыяҗын нигезләүне, субсидия суммасын исәпләү-нигезләүне дә кертеп, үз эченә алган аңлатманы, шул исәптән Чараны үткәрү чыгымнарының беренчел сметасын.

Гамәлгә куючы белән Учреждение арасында бухгалтерлык хезмәте күрсәтүгә килешү төзелүен исәпкә алып, түбәндәге документларны тапшыру таләп ителми:

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең «Хезмәткәрләрнең санын, хезмәт шартларын һәм хезмәт өчен түләнүне, оешмаларның һөнәри төркемнәр буенча хезмәткәрләргә ихтыяҗын, дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составын федераль статистик күзәтүне оештыру өчен федераль статистик күзәтү формаларын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 457 номерлы боерыгы белән расланган, Учреждение тарафыннан хисап кварталыннан соң килъче айның беренче числосына тутырылган «Хезмәтләрнең саны һәм хезмәт хакы турында белешмәләр» П-4 номерлы федераль статистик күзәтү формасын;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан кулланыла торган беренчел исәпкә алу документлары һәм бухгалтерлык исәпкә алу регистры формаларын һәм аларны куллану буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2015 елның 30 мартындагы 52н номерлы боерыгы белән расланган 0504401 формасы буенча Учреждение тарафыннан хисап кварталының узган айлары өчен тутырылган хисап-түләү ведомостен;

гариза бирү планлаштырылган айның беренче числосына салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар,

җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләре үтәлү турында Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штрафлар, пенялар, штрафлар түләү йөкләмләренең үтәлүе турында белешмә формасын һәм аны электрон рәвештә тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым органы белешмәсе;

гариза бирү планлаштырылган айның беренче числосына Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча вакытында түләнми калган бурыч булмау турында  Учреждение җитәкчесе һәм баш бухгалтеры, баш вәкаләтле заты имзасы куелган белешмәне, моңа учреждениене үзгәртеп кору яисә бетерү буенча чаралар күрүгә, авария (гадәттән тыш) хәлен кисәтүгә, гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта зыяннарны бетерү һәм торгызу эшләрен башкаруга, законлы көченә кергән суд актлары буенча бурычларны каплауга, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклар керми.

Документлар һәм Гариза Учреждение тарафыннан электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасын кулланып электрон рәвештә бирелгән очракта, аларга Учреждение җитәкчесенең яисә Учреждение җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручының электрон имзасы куелган булырга тиеш.

2.2. Гариза бирелә торган айның беренче числосына Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;

Учреждениенең учреждениене үзгәртеп төзү яисә бетерү чараларын гамәлгә ашыруга, авария (гадәттән тыш) хәлне кисәтүгә, авария (гадәттән тыш) хәл килеп туганда зыяннарны бетерү һәм торгызу эшләрен башкаруга, законлы көченә кергән суд актлары буенча бурычларны каплауга субсидияләр бирелү очракларыннан, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы юк;

Учреждение әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алмый.

2.3. Субсидияләр алу өчен документлар Гамәлгә куючы тарафыннан журналга

кергән көнендә үк теркәлә, ул номерланган, тегелгән һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән алып биш эш көне эчендә аларны карый, аларда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидияләр бирү турында йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

2.4. Агымдагы финанс елында Учреждениягә бирелә торган субсидияләр күләме (С) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = З_1,$$

монда:

$З_1$ - автобусларны арендалау чыгымнарын түләү чыгымнары.

Гамәлгә куючыга законнарда билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән субсидияләр бирүгә финанслауның иң чик күләмнәре югарыда күрсәтелгән формула буенча исәпләнгән субсидияләр күләменә туры килмәгән очракта, Учреждениегә субсидияләр Гамәлгә куючыга җиткерелгән субсидияләр бирү өчен финанслауның иң чик күләмнәре чикләрендә бирелә.

2.5. Гамәлгә куючы һәм Учреждение арасында субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүнең типлаштырылган формасын раслау турында» 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүнең типлаштырылган формасына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 20 декабрендәге 17-131 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба - Килешү) төзелә, ул түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә ала:

субсидия бирү максаты;

субсидия күләме;

субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планы;

субсидияләр бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

субсидияне күчерү сроклары (графигы);

субсидия финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында, килешүне үтәү турында;

килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе Учреждение тарафыннан үтәлмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Гамәлгә куючыга субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта;

Гамәлгә куючы карары буенча килешүне бер яклы тәртиптә вакытыннан алда туктату өчен нигезләр, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле:

Учреждениене үзгәртеп коруга (кушу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яисә бетерүгә бәйле;

әлеге Тәртиптә һәм (яисә) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатлары һәм шартлары Учреждение тарафыннан бозылуга бәйле;

килешүне Учреждение тарафыннан берьяклы тәртиптә өзүне тыю.

Кирәк булганда, Гамәлгә куючы һәм Учреждение килешүгә өстәмә килешү яисә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү яки килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

2.6. Гамәлгә куючы Субсидияләр бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә Учреждениегә субсидияләр күчерә.

2.7. Учреждениягә бирелгән субсидияләр чаралары белән операцияләр Учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган аерым хосусый счетларында исәпкә алына.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган Учреждение чыгымнарын санкцияләү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.8. Агымдагы финанс ел дәвамында субсидияләр акчалары исәбеннән башкарыла торган чыгымнарны өстәмә финанслау кирәк булган очракта, Учреждение, өстәмә финанс ресурслары кирәклеген исәпкә алып, субсидияләр күләмен арттыру турында тәкъдим белән Гамәлгә куючыга мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

2.9. Бирелә торган субсидияләр күләмен арттыру турында тәкъдим белән Учреждение мөрәҗәгать иткән очракта, Гамәлгә куючы кергән мөрәҗәгатьне теркәү датасыннан унбиш эш көне эчендә Учреждениенең әлеге тәкъдимен һәм өстәмә финанс чараларын бүлеп бирү кирәклеген тәкъдим ителгән исәпләүне карый, бюджет ассигнованиеләре чикләрендә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган өстәмә килешүләр төзү юлы белән килешүгә үзгәрешләр кертүне тәкъдим итә.

2.10. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе - хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылында эш урынына кадәр планлаштырылган алып баруларның һәм кире алып кайтуларның саны 100 процентка үтәлү.

## 3. Хисап бирүгә таләпләр

3.1 Учреждение Гамәлгә куючыга түбәндәге срокларда хисап тапшыра:

субсидия бирү елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап;

субсидия бирү елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында хисап .

Учреждение Гамәлгә куючыга, субсидияләр бирү аеннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында әлеге Тәртипкә кушымта итеп бирелгән форма буенча (2 нче кушымта) хисап бирә.

хисап елының соңгы аеның 25 числосыннан да соңга калмыйча, килешүнең үтәлеше турында Гамәлгә куючы тарафыннан раслана торган форма буенча хисап, анда субсидияне гамәлгә ашыру турында белешмәләр дә бирелә

3.2. Бюджет акчалары керүне һәм аларны тотуны бюджет (бухгалтерлык) исәбен алып бару Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алып барыла.

## 4. Максатларның үтәлешен, субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

4.1. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс контроле вәкаләтле органы мәҗбүри тәртиптә Учреждениягә субсидияләр бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен тикшереп тора.

4.2. Учреждение субсидия алу өчен яисә субсидия куллану турында дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырган, әлеге Тәртип нигезендә субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шулай ук субсидияне тоту максатларын бозган өчен, әлеге Тәртипнең 3 бүлегендә күрсәтелгән хисаплылыкны тапшырмаган өчен, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән өчен җаваплы.

Учреждениегә тиешле йөкләмәләрне үтәүгә комачаулаучы җиңеп булмый торган көчләрнең документаль расланган хәлләр барлыкка килү Учреждениене җаваплылык чараларын куллануда азат итү өчен нигез булып тора.

4.3. Субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланган очракта, Гамәлгә куючы һәм (яисә) дәүләт финанс контроле органы күрсәтелгән фактны ачыклау датасыннан 10 эш көне эчендә Учреждение адресына субсидия чараларын кире кайтару турында язма таләп җибәрә.

Гамәлгә куючы һәм (яисә) дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәсендә билгеләнгән субсидияләр бирү һәм алардан файдалану буенча хокук бозулар ачыкланган очракта, субсидия күрсәтелгән фактны ачыклау көненнән алып 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

Килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, субсидия Учреждениягә тиешле таләп Гамәлгә куючы һәм (яисә) дәүләт финанс контроле органы тарафыннан куелган көннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

4.4. Әлеге Тәртипнең 4.3 пунктында күрсәтелгән субсидияләрнең калган өлешләрен кире кайтару сроклары бозылган очракта, Гамәлгә куючы эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә субсидияне, калган субсидияләрне кире кайтару срогы тәмамланган көннән алып, күрсәтелгән акчаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләтү чараларын күрә.

4.5. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләре, хисап финанс елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш, моңа күрсәтелгән чараларга ихтыяҗ булу турында Гамәлгә куючы тарафыннан карар кабул ителгән очраклар керми.

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаларны әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка юнәлтү ихтыяҗы булган очракта, Учреждение Гамәлгә куючыга, хисап финанс елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, мондый ихтыяҗның булуы нигезләнгән мәгълүмат бирә.

Гамәлгә куючы, Учреждениедән әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлешен агымдагы финанс елына җибәрүгә Учреждение ихтыяҗы булу яисә булмау турында бюджет законнары нигезендә карар кабул итә.

Гамәлгә куючы агымдагы финанс елында Учреждение ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше Гамәлгә куючы белән Учреждение арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

4.6. Агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1.3 пункты нигезендә билгеләнгән максатка ирешү өчен финанс тәэминаты чыганагы булып торган түләүләрне кире кайтарудан кергән кертемнәр булган очракта, гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында билгеләнгән максатка ирешү өчен аларны куллану турында карар кабул итә, моның өчен нигез итеп Учреждениенең элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан акчалар финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре, шулай ук Учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләр күләмен (физик затлар тарафыннан түләү йөкләмәләреннән тыш) раслаучы документлар (документлар күчермәләре) булган мөрәҗәгате алына, ул субсидия бирелгән елдан соң килүче елның 20 эш көне эчендә бирелә (алга таба - элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан акчалар буенча Учреждение мөрәҗәгате).

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында билгеләнгән максатка ирешү өчен финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булып торган элек Учреждение тарафыннан башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән акчаларны агымдагы финанс елында файдалану турында карарны элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан акчалар буенча Учреждение мөрәҗәгате кергән вакыттан алып биш эш көне эчендә кабул итә.

Хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урынына вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

Гариза № "__" ________, 20___ ел
"___" _____________, 20____ елга субсидия алу өчен

_____________________________________________________________
(учреждениенең исеме, ИНН/КПП)

______________________________________________________
(субсидияләр төре)

| N т/б | Максатчан статья исеме | Чыгымнарның бюджет классификациясе коды | Субсидияләрне тотуның максатчан юнәлеше | Агымдагы финанс елына сорала торган субсидияләрнең суммасы, сум. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| Гариза буенча БАРЛЫГЫ | | | | |

Әлеге гаризага түбәндәге документлар теркәп бирелә:
_____________________________________________________________
Учреждение җитәкчесе _______________________/ ___ ;

Мөһер урыны

Хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авылына эш урынына вахта белән алып баруны һәм кире алып кайтуны оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

"______" __________, 20__ ел торышына субсидияләр бирү нәтиҗәләренә (контроль нокталар) (1) ирешү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап

```
                                                           ┌──────────┐
                                                           │ КОДЛАР  │
                                                           ├─────────┤
Алучының җыелма реестр буенча исеме                       │
                                 _________________    ИНН│          │
Дәүләт хакимияте башкарма органы -
Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын │
баш бүлүченең                              │
җыелма                                реестр                    буенча
│
                                 _________________ │   │исеме
Документ төре ____________________________________     ├─────────────┤
(беренчел - «0», төгәлләштерелгән - «1», «2», «3», «...»)            │
Ешлык: айлык; квартал; еллык                 │   │
                                                           │          │
Исәпләү берәмлеге: сум.                                        ОКЕИ буенча
│   383    │
                           └──────────┘
```

| Субсидияләр бирү нәтиҗәсе, контроль нокталар | | | Үлчәү берәмлеге | | Билге | | |Ирешү срогы | | Статус (5) | Кире кагу сәбәбе (6) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исеме | код | учреждение тибы | исеме | ОКЕИ коды | план буенча | фактта (2) | фараз буенча (3) | план буенча | фактта (фараз буенча) (4) | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Субсидияләр бирү нәтиҗәсе (7) | | | | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль нокталары (8) | x | | | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| план чорының контроль нокталары (9) | x | | | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | |

Җитәкче (вәкаләтле зат)
Алучы ___________________________________ _____________________

(вазыйфа) (имза) (имзаны аңлатып язу)
Башкаручы __________________________________ ______________________
(вазыйфасы) (фамилиясе, инициаллары) (имзасы)

«__» ___________, 20__ ел

(1) Хисап күрсәткечләре узган хисап чорларында субсидияләрне, контроль нокталарны бирү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат нигезендә төзелә, аларның план күрсәткечләренә ирешү срогы хисап датасына, узган хисап чорларында ирешүгә планлаштырылган контроль нокталар, шулай ук казанышлары хисап чорыннан соң килүче өч ай дәвамында планлаштырылган субсидияләрне, контроль нокталарны бирү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат нигезендә формалаштырыла. Килешүдә федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары нигезендә саклана торган дәүләт сере яисә башка саклана торган белешмәләр булган очракта, тиешле тамга («хезмәттә файдалану өчен»/ «яшерен» / «бөтенләй яшерен») һәм нөсхәнең номеры куела.

(2) 1 нче графада билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәсенең һәм контроль нокталарның фактта ирешелгән күрсәткечләре күрсәтелә.

(3) 1 нче графада билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәсенең һәм контроль нокталарның фактта ирешелгән күрсәткечләренең тиешле хисап датасына ирешү срогы килеп җиткән 6 нчы графада күрсәтелгән планлаштырылган күрсәткечләреннән тайпылуы күрсәтелә.

(4) 1 нче графада күрсәтелгән субсидияләр бирү нәтиҗәсенә һәм контроль нокталарна үрешү срогы күрсәтелә. Субсидияләр бирү нәтиҗәсенең, контроль ноктаның 6 нчы графада билгеләнгән күрсәткече хисап чорында ирешелмәгән (өлешчә ирешелгән) очракта, билгеләнгән күрсәткечкә ирешүнең фаразланган срогы күрсәтелә.

(5) «О» статусы - тайпылышлар булмаганда, «1» - тайпылышлар булганда күрсәтелә.

(6) Субсидияләр бирү нәтиҗәсенең, контроль ноктаның билгеләнгән датага план күрсәткече фактта ирешелмәгән очракта, план күрсәткеченнән читкә тайпылу сәбәбе күрсәтелә.

(7) Субсидияләр бирү нәтиҗәсенең исеме күрсәтелә.

(8) Ирешү датасы хисап чорында килеп җиткән контроль ноктаның

исеме күрсәтелә.

(9) Ирешү хисап чорыннан соң килүче өч ай дәвамында планлаштырылган контроль ноктаның исеме күрсәтелә.